| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от 04.02.2022** г. Казань **№ 27/2022**

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 10 июлендәге 262/2020 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 2033 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 10 июлендәге 262/2020 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 22.12.2020 №718/2020, 22.10.2021 №594/2021 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Д.А. Сапожников

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының
04.02.2022 № 27/2022
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 10 июлендәге 262/2020 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.5.1 пунктында:

б) пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Хисапчы хисаплылыгы гаризага, әгәр ул «Хисапчылык исәбе турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы федераль законның 18 статьясында каралган хисапчы (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсында булмаса, теркәлә. Җайга салына торган оешма хисапчы (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында, хисапчылык хисабын бирсә, җайга салу органы ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын кулланып, әлеге дәүләт мәгълүмат ресурсыннан шундый хисап ала;»;

түбәндәге эчтәлекле о) пунктчасын өстәргә:

«о) җылылык челтәрләре хуҗасының җылылык челтәрләренә кертү критерийларына туры килүен раслаучы документлар күчермәләре һәм башка мәгълүмат.»;

2.8 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләренең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим бирү срокларын үтәмәү;

мөрәҗәгать итүченең җылылык челтәрләренең милекчеләрен яисә башка законлы хуҗаларын җылылык челтәрләре оешмаларына кертү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 8 августындагы 808 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру кагыйдәләрендә каралган критерийларга туры килмәве (әлеге абзац таләбе 2022 елның 1 сентябреннән гамәлдә була).».